# ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ ЯЗУЧЫЛАРЫ

(биобиблиографик белешмәлек)

төзүче: Роза Хәмидуллина

2017 ел

**ББК** 83.3 (2 Рос=Тат)
Я 64

**ТӨЗҮЧЕ:**

**Роза Галимулла кызы ХӘМИДУЛЛИНА,**
Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсенең әдәбият тарихы музее җитәкчесе,
Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре

Я 64 **Яр Чаллы язучылары**: Биобиблиографик белешмәлек / төз. Роза Хәмидуллина. – Яр Чаллы, 2017.

Бу җыентыкта Яр Чаллы төбәге язучылары, “Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсе әгъзаларының кыскача биографияләре, төп басма китаплары исемлеге бирелә.

Китап шәһәребез язучылары белән кызыксынучыларга, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, китапханәчеләргә ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

# II бүлек – «ЛӘЙСӘН»
# әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары

| № | Фамилия, исеме, атасы исеме | Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат | Төп басма китаплары |
|---|---|---|---|
| **1** | **Рәсим АБДУЛЛИН (1929 – 2005)**  | Рәсим Мансур улы Абдуллин 1929 елның 1 июлендә Тукай районы Кызыл Байрак авылында туган. Юмористик хикәяләр һәм шигырьләр яза. Шәһәр, республика күләмендә вакытлы матбугатта шигырьләре бик еш урын ала.<br>Ул 2005 елның 2 сентябрендә вафат була. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **2** | **Наилә АБДУЛЛИНА** | Наилә Абдуллина 1955 елның Пермь өлкәсенең Кизел шәһәрендә туган.<br>Балачагы Тукай районы да Бордыбаш авылында үтә.<br>Минзәлә медицина училищесын тәмамлый, күп еллар шифаханәдә эшли.<br>1980-2000 елларда Чаллы язучылар берлеге оешмасы каршында оешкан “Ләйсән” әдәби берләшмәсенә йөри. | Алла бабай чишмәсе: шигырьләр // Аргамак. – 1998. – № 5-6 (Балалар өчен әдәби кушымта). |
| **3** | **Энҗе АВЗАЛОВА** | Энҗе Зәки кызы Авзалова 1982 елның 30 июнендә Казан шәһәрендә туа. 1989 елда Минзәлә районының Кадрәк авылы мәктәбендә гел бишле билгеләренә генә укып, алты яшеннән шигырьләр яза. Аннан Чаллы шәһәренең 2 нче татар гимназиясен тәмамлый.<br>Энҗе Авзалова югары белемне Казан дәүләт университетында ала. Ул көнчыгыш телләре факультетында укый. 2004 елда аны алтын медаль белән тәмамлый, филолог, татар теле әдәбияты, төрек теле укытучысы белгечлеге ала. Энҗе татар, русс теленнән тыш, | Кояшка хат: шигырьләр / кереш сүз белән Г. Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр. – 1994.<br>Зәңгәр чәчәк: шигырьләр. – Минзәлә, 1994.<br>Серле чишмә: шигырьләр // Аргамак. – 1997. – № 4 (Балалар өчен әдәби кушымта). |

| | | | |
|---|---|---|---|
| |  | төрек, инглиз телләрен яхшы белә, гарәп, әзербайҗан телләрендә аралаша ала. Университетны тәмамлагач, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы аны Төркиягә, Анкара университетына, магистратурага укырга җибәрә. Анда ул өч ел «тюркология» белгечлеге буенча белем ала. Энҗе чит илдә мәхәббәтен – Илһанны очрата. Әнисендә - төрек, әтисендә башлыча инглиз каны аккан Илһанны үзенә яр итеп сайлый.<br>Энҗе Авзалова кечкенәдән үк шигырьләр иҗат итә. 11 яшьтә Энҗенең «Кояшка хат» исемле беренче китабы Казанда дөнья күрә. Татарстан Республикасының милли китапханәсе үткәргән «Ел китабы-94» исемле конкурсында китап беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Хәзерге көндә ул Төркиядә яши. | Якты алан: шигырьләр // Аргамак. – 1999. – № 3 (Балалар өчен әдәби кушымта). |
| **4** | **Альбина АФЗАЛОВА**<br> | Альбина Өлфәт кызы Афзалова-Хөрмәтуллина 1957 елның 14 декабрендә Актаныш районы Алма-Ата авылында авылында туа. 1975 елда Киров урта мәктәбендә белем ала. Читтән торып Алабуга педагогия институтын тәмамлый.<br>Яшьлек романтикасы аны Чаллы шәһәренә КАМАЗ заводларының берсенә эшкә алып килә. Заводта эшләгән 1976-1980 елларда шәһәрнең яшь иҗат көчләрен туплаган «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә йөри. Ул олпат шагыйрь һәм язучыларның хәер-фатыйхасын алып, берсеннән-берсе матур шигырьләр иҗат итә. 1982 елда туган ягына кайтып, Актаныш янгын сакчыллыгы бүлегендә инструктор булып эшли башлый. Район газетасы каршындагы «Агыйдел дулкыннары» иҗат берләшмәсенә йөри, аның сәркатибе итеп сайлана.<br>Альбина Афзалованың беренче шигырьләре шәһәребездә чыга торган «Кама таңнары» һәм «Якты юл» газеталарында дөнья күрә. 1997 елда Казанда Актанышта яшәп иҗат итүче шагыйрь, прозаикларның иҗат җимешләрен берләштергән «Агыйдел дулкыннары» күмәк китабында аның шигырьләре дөнья күрә.<br>Бүгенге көндә Актанышта эшләп килүче «Агыйдел дулкыннары» әдәби берләшмәсе әгъзасы. | Һәрбер җырым – йөрәк хисем минем: шигырьләр. – Актаныш: ҖЧҖ ФҖБ «Актаныш» басмаханәсе, 1990.<br>Актанышым – ак калам: шигырьләр. – Чаллы: «Чаллы» нәшр., 2001.<br>Гамьле гомер: шигырьләр һәм җырлар. – Актаныш: ҖЧҖ ФҖБ «Актаныш» басмаханәсе, 2006.<br>Җылы эзлим: шигырьләр. – Казан. – «Татмедиа», «ПИК» «Идел-Пресс», 2012. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **5** | **Рәкит ӘБДЕЛМАНОВ**<br> | Рәкит Җәүдәт улы Әбделманов (Рәкит Атлас) 1960 елның 22 мартында Башкортостан Республикасы Күмертау районы Аллабирде авылында туа. 1983 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши.<br>Рәкит Җәүдәт улының хикәяләр һәм тарихи эсселәр тупланган “Аллабирде” исеме астында беренче китабы 1996 елда дөнья күрде.<br>Рәкит Атлас – 1996 елдан бирле Чаллы язучылар берлеге оешмасы каршында оешкан “Ләйсән” әдәби берләшмәсенә йөри. | Аллабирде: хикәяләр, һәм тарихи эссе. – Яр Чаллы, 1996.<br>Хыял атым: шигырьләр, поэмалар, җырлар. – Яр Чаллы, 2014.<br>Сулыш: повесть, кыйсса, шигырьләр, җырлар. – Яр Чаллы, 2015.<br>Җаным тама шигырьләр, җырлар, бәян. – Яр Чаллы, 2016.<br>Әтәч елы шигырьләр. – Яр Чаллы, 2017. |
| **6** | **Дәмниха ӘЛМӨХӘММӘТОВА (1924 1997)**<br> | Дәмниха Шакирҗан кызы Әлмөхәммәтова 1924 елның 24 апрелендә Татарстан Республикасының Сарман районы Иске Имән авылында туа. Авылда җидееллык мәктәп, аннан Зур Нөркәйдә урта мәктәпне тәмамлый. Минзәлә педагогия училищесыннан соң эшкә туган ягына кайта – бик күп еллар Иске Дөреш авылында балалар укыта.<br>Бездә китаплар күп иде, әткәй белән әнкәй бер-берсе белән ярыша-ярыша китаплар укый торганнар иде. Әнкәебез кичләрен сукыр лампа яктысында көйли-көйли Сак-Сок, Таһир-Зөһрә, Йосыф кыйссаларын безгә укырга да вакыт таба иде. Бераз үсә төшкәч, үземә дә китап «җене» кагылды. Иптәшләремне янымa җыеп шигырь, бәет, хикәятләр сөйләп таң калдыра торган идем».<br>Дәмниха Әлмөхәммәтова 1997 елның 26 ноябрендә вафат. | Истәлекле шомырт: шигырьләр. – Чаллы: «КАМАЗ» нәшр., 1993. |
| **7** | **Наил ӘХМӘТҖАНОВ**<br> | Наил Әнвәр улы Әхмәтҗанов 1960 елның 16 октябрендә Татарстан Республикасынң Азнакай районы Урсай авылында туа. Азнакай шәһәрендә дүртенче санлы урта мәктәпне тәмамлый. Казан медицина училищесында белем ала. 1982-1985 елларда Азнакай шәһәре санэпидемстанциясендә хезмәт юлын башлап җибәрә.<br>1985 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши. Шул еллардан бирле КАМАЗ заводының «Тимер-бетон эшләнмәләр» заводында формаларга салучы вазыйфасын башкара. Өйләнгән, ике кыз, бер малай үстерә.<br>Балачактан китапка гашыйк. Наилнең үткен мәкаләләре, | Хыял канатларында: хатирәләр, истәлекләр. – Яр Чаллы, 2015. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | юморескалары, фантастик әсәрләре бик еш кына «Таң йолдызы», «Шәһри Чаллы», «Аргамак» (1998-1999) битләрендә басыла.<br>1998 елдан Яр Чаллы Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | |
| 8 | **Флүсә БАРИЕВА**<br> | Флүсә Котдүс кызы Бариева 1949 елның 8 мартында Татарстан Республикасының Минзәлә районы Бикбау авылында туа. Авылда урта мәктәпне һәм Казан авыл хуҗалыгы институтының икътисад бүлеген тәмамлый. Дистә елдан артык Пермь өлкәсенең Чайковский шәһәрендә яши. 1985 елда Чаллы шәһәренә әйләнеп кайта. Күп еллар буе «Спецатоммонтаж» трестының монтажлау идарәсендә баш хисапчы булып хезмәт итә.<br>Беренче шигъри юллары 2000 елда языла. Шигырьләрендә уй-фикер, кичерешләре, гади сөйләм теле белән беркайчан да әйтә алмас сүзләре. | Бәхет җиле: шигырьләр. – Яр Чаллы: 2002. |
| 9 | **Дамир ВАГЫЙЗОВ (1936-2016)**<br> | Дамир Харрас улы Вагыйзов 1936 елның 1 мартында Татарстан Республикасының Лаеш районы Татар Агайбашы авылында укытучы гаиләсендә туа. Татар Сараланы урта мәктәбендә белем ала. Казан дәүләт университының журналистика бүлеген тәмамлый.<br>Чистай шәһәре газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җиде ел дәвамында Татарстан радиосының штаттан тыш хәбәрчесе вазыйфаларын башкара.<br>1970 елның ахырында, Чаллыга, КАМАЗ төзелешенә җибәрелә. Шәһәр газетасы редакциясендә бүлек мөдире, редактор урынбасары булып эшләгәннән соң, 1976 елда яңа оештырылган Тукай районының «Якты юл» газетасына баш редактор итеп билгеләнә. Лаеклы ялга чыкканчы шунда эшли.<br>Дамир Харрас улының күп кенә юмористик хикәяләре, әдәби очерклары, зарисовкалары журналларда, газеталарда басыла.<br>Дамир Вагыйзов – Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, КАМАЗ төзелеше ударнигы. | Үч: повестьлар, хикәяләр /. – Яр Чаллы: «Ислам нуры» дини эшмәкәрлек үзәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять типографиясе, 2008. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **10** | **Мөнип ГАЗАР** | Мөнип Газарның 1980 еллар башында шигырьләре шәһәркүләм вакытлы матбугат битләрендә еш басыла. | Җиде җил үзәне: КАМАЗ турында язылган шигырьләр, җырлар, поэмалар / төз. Рөстәм Мингалимов. – Казан, 1975.<br>«Ләйсән» – моңлы бишегебез»: Чаллы шәһәре «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең күмәк җыентыгы / төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова. – Яр Чаллы, 2009. |
| **11** | **Әлфия ГАБДРӘШИТОВА**<br> | Әлфия Зыя кызы Габдрәшитова 1952 елның 25 мартында Башкортостан Республикасының Балтач районы Иске Балтач район үзәгендә туа. Туган авылы мәктәбендә урта белем ала. Аннан Свердловск шәһәрендә педагогия институтының рус теле әдәбияты факультетын тәмамлый. Югары белемле Әлфия Зыя кызы хезмәт юлын туган республикасының Көнтүгеш авылы мәктәбендә башлап җибәрә. Мәктәптә ун ел укытканнан соң, 1985 елда, Габдрәшитовлар гаилә Чаллыга күчеп киләләр. Әлфия Зыя кызына башта Чаллыда төрле эшләрдә хезмәт куярга туры килә. Ә 1991 елдан Мулланур Вахитов исемендәге гимназиядә укытучы, директор урынбасары булып эшли.<br>2013 елдан Яр Чаллы Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | Кояш - мин сиңа охшаш: шигырьләр. – Казан: “Идел-Пресс”, 2016.<br>Матурлык эзли күңел: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2016. |
| **12** | **Әхәт ГАЙНУЛЛИН**<br> | Әхәт Гайнуллин 1929 елда Татарстан Республикасының Буа районы Аксу авылында туган.<br>1971 елның 21 июлендә КАМАЗга килә. «Башсантехмонтаж» трестының СМУ-1 оешмасында комсомоль-яшьләр бригадасын җитәкли. Ике тапкыр ЦК ВЛКСМ «Молодой коммунист» журналының «Красная гвоздика» призына лаек була.<br>Күп кенә хикәяләр һәм ике шигъри китап авторы.<br>Каты авырудан соң вафат була. | Тәрәзәдә утлар: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967.<br>Кил син безнең урамнарга: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **13** | **Рафаэль ГАЙНУЛЛИН (1942-2014)**<br> | Рафаэль Габделхак улы Гайнуллин 1942 елның 5 гыйнварында Чирмешән районы Тукай поселогында туа. Алты яшендә беренче класска укырга керә. Әтисе авылда беренче гармунчы һәм балта остасы, әнисе Зәкия апа оста җырчы була.<br>1948-1955 елларда Иске Кади авылында җидееллык мәктәптә белем ала, аннан авылның кичке мәктәбендә сигез – тугызынчы классларын, ә 1960 елда Лашман урта мәктәбен тәмамлый.<br>Шигырьләрне яшьтән яза. Халык арасында популярлашкан җырларыннан «Яр Чаллы» (Азат Хөсәенов), «Әткәемә хат» ( Дамир Закиров) һәм башкалар.<br>2014 елда вафат булды. | Яшәү хакы: җырлар / кереш сүз белән И. Закиров. – Яр Чаллы: «Яр Чаллы» типографиясе, 2011. |
| **14** | **Гамир ГАЙФЕТДИНОВ (1941-1998)**<br> | Гамир Солтан улы Гайфетдинов 1941 елның 1 июлендә Зәй районы Биш Субашы (Пуст-Ашыт) авылында туа. 1958 елда Түбәнбиш урта мәктәбен тәмамлап, Чистай елга техникумына укырга керә. 1962-1965 елларда Совет армиясе сафларында хезмәт итә. Читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый.<br>1966-1969 елларда «Коммунизм байрагы» газетасында әдәби хезмәткәр, шәһәр комсомол оешмасында инструктор вазыйфаларын башкара. 1969-1973 елларда республика радиотапшыру һәм телевидениянең Чаллыдагы үз хәбәрчесе булып эшли. 1976 елдан «Якты юл» газетасының беренче көннәреннән башлап авыл хуҗалыгы мөдире була. Чаллы халык театры артисты булып дистәләгән рольләр тудыра.<br>Татарстанның Атказанган мәдәният хезмәткәре (1990 ел, 25 август) дигән мактаулы исем иясе, «Иң актив һәм нәтиҗәле хезмәте өчен» һәм «Социалистик Татарстан» газетасының 60 еллыгы уңаеннан мактау кәгазе, Татарстан мәдәният министрлыгының «Үзешчән театрда актив катнашып зур уңышларга ирешкән өчен» мактау грамоталары белән бүләкләнә.<br>Гамир Гайфетдинов 1998 елның 28 ноябрендә вафат була. | Куш йөрәкләр: шигырьләр / кереш сүз А. Хәлим. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2004. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | **Энҗе ГАЙФЕТДИНОВА**<br> | Энҗе Зиннур кызы Гайфетдинова 1935 елның 12 апрелендә Татарстан Республикасының Тукай районы Калмаш авылында туа. Туган авылында җидееллык мәктәптә, аннан Күзкәй авылында укуын дәвам итә.<br>1955 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши. Хезмәт юлының 37 елын мәдәният өлкәсендә эшләүгә багышлый. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллы халык театры артисткасы булып дистәләгән рольләр тудыра: Т. Гыйззәт «Ялкын» (Фәрхиназ), Ә. Гаффар «Язлар моңы» (Фәрдәнә), М. Әмир «Хөррият» (Бибисара), Н. Исәнбәт «Рәйхан» (Рәйхан), Ю. Әминов «Өти балак» (Гөлүзә) һ.б.<br>Күпсанлы җырлар авторы. Шәһәребездә яшәп иҗат итә. | Куш йөрәкләр: шигырьләр /кереш сүз А. Хәлим. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2004.<br>Яраталмыйм синнән бүтәнне: җырлар. - Яр Чаллы, 2009.<br>Еракдагы йолдыз: шигырьләр / кереш сүз Г. Шаһи. – Яр Чаллы: «Ислам нуры» басмаханәсе, 2010.<br>Дүрт шәхескә бер бәхет: җырлар аудиокассета. – Яр Чаллы, 2010. |
| 16 | **Хәким ГАЛИДӘН**<br> | Габделхәким Әхмәтзакир улы Насыров (Хәким Галидән) 1944 елның 24 июлендә Самара өлкәсенең Гали авылында туа.<br>Бала вакыттан ук рәсем ясау белән мавыга, 1962 нче елны, Похвистнево райком комсомолы тәкьдиме белән, Татарстанның Лениногорск шәһәре музыка һәм художество училищесына рәссамлыкка укырга керә. Өченче курстан, 1964 елны, Совет Армиясенә алына. Армиядән соң укуын дәвам итә.<br>1973 елны Яр Чаллы шәһәренә гаиләсе белән күченеп киләләр. Инструментлар заводына грузчик, аннан мастер булып эшли. 1996 елның июленә кадәр заводта хезмәт итә.<br>1980 еллар уртасында, язучы Әхмәт Дусайлы киңәше белән, Язучылар оешмасы каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә килә. Шул еллардан бирле яза | Дала җилендә әрем тәме: хикәяләр һәм шигырьләр. – Яр Чаллы: 2013. |
| 17 | **Гыйлемхан ГАРИПОВ**<br> | Гыйлемхан Гарипов Мамадыш якларында туып үсә. КАМАЗ йөрәге булып саналган ТЭЦта эшли. Оста гармунчы була. Буш вакытларында үзенең хыяллары, уй-тойгылары һәм якты киләчәге турында гармун телләре белән сөйләшә, аларга үзенең йөрәгендәге иң татлы, иң яшерен сүзләрен дә ышанып тапшыра ала. Ә бетмәс-төкәнмәс уйлар гармун моңына төренеп шигырь булып шытып чыгалар.<br>Самими һәм эчкерсез шигырьләрендә аның күпкырлы дөньясы, янып яшәве, туган илгә, туган җиргә, йөрәк түренә кереп урнашкан бер кешегә, үзе яраткан хезмәткә мәхәббәте чагыла. Шигырьләрдә – аның эзләнүе, аның табышлары. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **18** | **Салават ГАТАУЛЛИН**  | Салават Гатауллин шигырьләр яза. Ул Ләйсән әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы була. 1980 еллар башында шигырьләре республика һәм шәһәркүләм вакытлы матбугат битләрендә еш басыла.<br>Өметле каләм иясен аяусыз үлем арабыздан алып китте. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **19** | **Нурислам ГАФИЯТОВ**  | Нурислам Хәлим улы Гафиятов 1961 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасының Аксубай районы Шәрбән авылында туа. Авыл мәктәбен тәмамлый, СПТУ да укып киң профильле механизатор һөнәрен үзләштерә.<br>Авторны бер дә юкка гына, җырчы шагыйрь, дип атамыйбыз. Буш вакытларында, бик моңайган, уйланган чакларында кулына гармунын алып уйный. Композиторларыбыз тарафыннан илледән артык шигырьләре көйгә салынган (О. Усманов, А. Шакиров, Р. Мифтахов, С. Миннеханов, Ф. Мортазин, А. Хөсәенов, Р. Андреев, Н. Шәймәрданов, И. Закиров, Р. Гобәйдуллин, Ф. Хатыйпов һ.б.).<br>Чаллы шәһәре Язучылар берлеге каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 2002 елдан бирле йөри. | Иң татлы хыялым: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2004.<br>Мин язларда яшим: шигырьләр / кереш сүз белән Ф. Җаббарова. – Яр Чаллы, 2006.<br>Моңлы йөрәк, Поющие сердца: шигырьләр, стихи / кереш сүз белән Г. Шаһи. – Казан, 2009.<br>Син булсаң янәшә: аудиокассета /. – Яр Чаллы: 2011. |
| **20** | **Габделбәр ГОМӘРОВ (1931-2006)**  | Габделбәр Гомәр улы Гомәров 1931 елның 30 апрелендә Татарстан Республикасының Саба районы Олыяз авылында 3 балалы гаиләдә туа. Туган авылында дүрт сыйныф ала, аннан Шекше авылына йөреп җиде сыйныфны укый. Унъеллык урта белемне Сеҗе урта мәктәбендә тәмамлый. 1950 елда Саба районы Эзмә авылына, РК ВЛКСМ тәкъдиме белән, математика укытучысы итеп билгеләнә.<br>Габделбәр Гомәр улы 13 яшендә яза башлый, һәм язмалары «Пионер каләме» – журналының Сигнал бүлегендә басылып чыга.<br>1951-1953 елларда Габделбәр Гомәров Тын океандагы Шантар утравында армия хезмәтен үти. Армия сафларыннан соң ул авыл мәктәбендә укытучы булып эшли, лектор буларак та күп эш башкара. Аның чыгышларын авылның ак сакаллы картларына кадәр яратып | И, гомер агышлары!..: истәлекләр, авыл мәзәкләре, хикәяләр һәм әкиятләр. – Чаллы: ҖЧҖ “Газета-китап нәшрияты”, 2002. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тыңлый. Әтисе саратов гармунында уйнарга, җырларга ярактангамы, музыкага да яшьтән үк һәвәс булып үсә ул. 13 яшьлек Габделбәргә әтисе Янил базарыннан гармун алып бирә. Малай башта шул ике рәтле гармунда, соңыннан баянда уйнарга өйрәнә.<br>1954 елда Габделбәр Гомәр улы читтән торып Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Югары белемле укытучы яшьтән сайлаган һөнәренә хыянәт итми, 35 ел балалар укыта.<br>2006 елның 9 гыйнварында вафат булды. | |
| **21** | **Гөлия ГЫЙЛӘҖЕВА**<br> | Гөлия Хамис кызы Гыйләҗева (Гыйльметдинова) 1965 елның 4 мартында Тукай районы (элеккеге Сарман) Иске Дөреш авылында колхозчы гаиләсендә туа. Туган авылында сигезьеллык, күрше Теләнче Тамак авылында унъеллык мәктәптә белем ала. Чаллы каласына килеп пешекчеләр әзерли торган училищега укырга керә. Пешекче һөнәрен үзләштереп, Зәй шәһәренә практикага җибәрелә. Ике ел хезмәт иткәннән соң, КАМАЗга оператор булып эшкә урнаша.<br>Гөлия Хамис кызы туганнарына, дуслары, хезмәттәшләренә багышлап шигырьләр, бәетләр иҗат итә. Аның шигырьләре КАМАЗ заводында чыгып килгән вакытлы матбугат битләрендә еш басылып килә.<br>2012 елдан «Лэйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **22** | **Рушания ГЫЙЛӘҖЕВА**<br> | Рушания Азат кызы Гыйләҗева 1956 елның 15 августында Татарстан Республикасының Әлмәт районы Яңа Кәшер авылында укытучылар гаиләсендә беренче бала булып туа. Туган авылында алты класс бетерә. Гыйләҗевлар гаиләсе 1969 елда Түбән Кама шәһәренә күченә. 1978 елда Ижау шәһәренең механика институтында экономист белемен ала. 1993 елдан Чаллыда яши. Бик күп еллар баш хисапчы вазыйфаларын башкара. 2008 елда шигырь, хикәя, мәсәлләр тупланган «Яшьлеккә хат» дигән тәүге китабы дөнья күрде.<br>Аның юмористик әсәрләре «Чаян» журналы, «Якты юл», «Татарстан яшьләре» газеталары битләрендә басылып килә.<br>2007 елдан Чаллы шәһәре Язучылар берлеге каршында оешкан «Лэйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. | Яшьлеккә хат: шигырьләр / кереш сүз Г. Шаһи / Р. Гыйләҗева. − Алабуга: «Алмедиа» басмаханәсе, 2008.<br>Алматау кошы: шигырьләр / кереш сүз Ф. Сафин. − Яр Чаллы: «Яр Чаллы типографиясе» ачык акционерлык җәмгыяте, 2011. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **23** | **Рим ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ**<br> | Рим Халиулла улы Гыйльметдинов 1954 елның 18 маенда Башкортстан Республикасының Борай районы Ваныш-Алпаутова авылында туа. Сигез сыйныфны Ваныш авылында тәмамлап, урта белемне Борай район үзәгендә ала. 1971-1972 елларда эретеп ябыштыручы һөнәренә укый. 1972-1974 нче елларда чит илдә армия сафларында хезмәт итә. 1975 елда Чаллы каласына кайта, КамАЗ заводына эшкә урнаша. 1977 елда заводның комсомол оешмасы милиция хезмәткәренә эшкә керергә җибәрә. Милиция сафларында хезмәт иткәндә читтән тотып укый һәм югары белем ала. 2000 елны подполковник дәрәҗәсендә отставкага китә.<br>2015 елдан Чаллы шәһәре Язучылар берлеге каршында оешкан «Лэйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. | Туган җирем: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2015. |
| **24** | **Нурия ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА**<br> | Нурия Тимергали кызы Гыйльметдинова 1941елның 14 декабрендә Татарстан Республикасының Саба районы Сатыш авылында хезмәткәр гаиләсендә туа.<br>Туган авылында җиде сыйныф тәмамлый, аннан соң кичке мәктәптә унъеллык белем ала. мәктәп елларында стена газеталарын чыгаруда актив катнаша. Көндезләрен унике яшьлек кыз туган авылы Сатыш телефон челтәрендә хезмәт итә. Гыйльметдинова Н. СССР Югары Советы Президиумының 1984 ел 14 сентябрендә чыккан указы нигезендә «За трудовую доблесть» медале белән бүләкләнә. Шул елларда Чаллы шәһәренең Комсомол районы советына ике тапкыр халык депутаты итеп сайлана.<br>2010 елдан «Лэйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. | Сагыну: җырлар, шигырьләр / кереш сүз белән М. Сафин. – Алабуга: «Андерсен» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, 2011.<br>Күңелем бизәкләре: истәлек-хатирәләр, шигырьләр Яр Чаллы, 2016. |
| **25** | **Тәбрис ГЫЙМАЛЕТДИНОВ**<br> | Тәбрис Харис улы Гыймалетдинов 1951 елның 29 мартында Татарстан Республикасының Чистай районы Нарат-Елга авылында туа. Туган авылында сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, Казанда киномеханиклар училищесында укый. Киномеханик, шофер булып эшли. Чистай совхоз техникумының механика факультетын, Казан дәүләт мәдәният институтының режиссерлар әзерләү бүлеген тәмамлый.<br>Бүгенге көндә Тәбрис Гыймалетдинов Чистай шәһәрендә эшләп килүче «Энҗеләр» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы: | Мәхәббәт чишмәсе: шигырьләр / кереш сүз Р. Бәшәр. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2001. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **26** | **Рузилә ҖАМАЛИЕВА**<br> | Рузилә Исхак кызы Җамалиева-Нәбиева 1954 елның 12 гыйнварында Татарстан Республикасының Балтач районы Карадуган авылында туа. Туган авылында унъеллык мәктәпне, аннан Алабуга сәнгать-мәдәният техникумын, соңыннан Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый.<br>1978-80 елларда «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. Хәзерге көндә Чаллы татар дәүләт драма театрында эшли. Рузилә Җамалиеваның Чаллы театрында «Чичиетта белән Мияубәкнең Яңа ел маҗаралары» һәм «Ак бүре» әкияте куелды. Театр артистлары, театр сәнгате турындагы язмалары газета-журнал битләрендә басылып килә. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **27** | **Зөлфия ҖИҺАН**<br> | Зөлфия Рамиз кызы Фаткуллина (Фазылбакова - Зөлфия Җиһан) 1964 елның 8 мартында Башкортостан Республикасының Туймазы районы Карат авылында, ишле гаиләдә дүртенче бала булып туа.<br>Туган авылында өч сыйныф, аннан күрше Оязытамак авылында уньеллык урта мәктәптә белем ала. Моң-җырга булган мәхәббәте аны Стәрлетамак шәһәренә мәдәният-агарту техникумының оркестр бүлегенә алып килә. Хезмәт юлын туган авылында башлап җибәрә.<br>1994 елдан Чаллы каласында яши. 1998 елда үзенең иҗат эшчәнлеген «КАМАЗ» мәдәният сараенда эшләп килүче «Сердәш» җыр төркемендә дәвам итә. Аннан «Чишмә» халыклар дуслыгы йортында, Тукай районы мәдәният йортында директор булып эшли.<br>Зөлфия Җиһан шигырьләр, көйләр яза. Үзенең өч дистәдән артык җырларын туплаган ике диск чыгара.<br>2012 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **28** | **Зәйнәп ҖИҺАНШИНА (1920 – 1982)**<br> | Зәйнәп Җиһанша кызы Җиһаншина 1920 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Чаллы (хәзерге Тукай) районы Биклән авылында ишле гаиләдә туа. Туган авылында җидееллык мәктәпне бетерә. Аннан соң, Казан финанс-экономика техникумына укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлап, Чаллы шәһәренә кайта. 1941 елда «Коммунизм байрагы» газетасы редакциясендә эшли башлый һәм үзенең утыз елга якын гомерен шушы мактаулы эшкә багышлый. Секретарь-машинистка, авыр сугыш елларында редактор, сугыштан соңгы чорда җаваплы секретарь һәм редактор урынбасары вазыйфаларын башкара.<br>Зәйнәп Җиһаншина егерме биш ел халык театрына йөри. Халык | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | арасында зур популярлык казанган, тамашачылар мәхәббәтен яулаган ветеран була. Талантлы журналист, артист, драматург. Ул «Төнге шәүләләр» пьесасын язып үзенең сәхнә әсәрләре тудырырга сәләтле икәнен раслый.<br>Зәйнәп Җиһаншина «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бергә ана булу дәрәҗәсе медале белән дә бүләкләнә. СССР журналистлар берлеге әгъзасы (1965).<br>Зәйнәп Җиһаншина 1982 елның 8 октябрендә вафат була. | |
| 29 | **Мөслиха ЗАКИРОВА**<br> | Мөслиха Кашафетдин кызы Закирова 1934 елның 24 августында Башкортостан Республикасының Ютазы районы Чишмә Каран авылында туа. Әтисе авылда агроном, аннан, колхоз рәисе, әнисе алдынгы колхозчылар рәтендә була. Мөслиха апа, колхоз юлламасы белән, авыл хуҗалыгы мәктәбендә укый, авыл бакчасында эшли: яшелчә, җиләк - җимеш үстерә.<br>1972 елдан шәһәребездә гаиләсе белән яши. Ире хәзерге көндә мәрхүм: ике кыз, бер ул тәрбияләп үстерәләр. Яшьтән үк шигырь язу гадәте, олыгайгач та тынгылык бирми. Шигырьләреннән күренгәнчә ул аны өлешенә тигән көмешем итеп кабул итә.<br>КАМАЗ төзелешендә эшли, бүгенге көндә лаеклы ялда.<br>Мөслиха Кашафетдин кызының шәһәр вакытлы матбугат битләрендә юмор-мәзәк шигырьләре еш басыла.<br>Чаллы Язучылар оешмасы каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | Шаян түти дәрес бирә: шигырьләр. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2007.<br>Тормыш бөртекләре: шигырьләр. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2008.<br>Замана көзгесе: шигырьләр. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2011. |
| 30 | **Мидхәт ИСЛАМОВ**<br> | Мидхәт Сәхап улы Исламов 1932 елның 15 мартында Татарстан Республикасының Аксубай районы Шәрбән авылында туган. Яр Чаллыда 1978 елдан бирле яши. Свердловскида политехник институт һәм аспирантура тәмамлап, озак еллар буе Новотроицк шәһәрендә (Оренбург өлкәсе) металлургия комбинатында эшли. 120 фәнни хезмәт һәм 80 уйлап табу авторы. | «Ләйсән» – моңлы бишегебез»: Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең күмәк җыентыгы / төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2009. – Б. 56. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **31** | **Зимфира ИСЛАМОВА**  | Зимфира Насыйх кызы Исламова 1958 елның 1 маенда Башкортостан Республикасының Бакалы районы Катай авылында туа. 1965-1975 елларда Катай урта мәктәбендә белем ала, 1980 елга кадәр Бөре дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетында укый. Кияүгә чыгып, гаиләсе белән Михайловка авылында яши башлыйлар. Михайловка урта мәктәбендә математика, немец теле, физика фәннәрен укыта.<br>1986 елда Чаллы шәһәренә күчеп киләләр. Зимфира Насыйх кызы алты ел 105 номерлы балалар бакчасында эшли. 1992 елдан Чаллының 37 мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта, I квалификацион разрядлы укытучы-методист.<br>2003-2006 елларда Чаллы Өзлексез педагогик белем бирү институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә икенче югары белем ала.<br>Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 2003 елдан бирле йөри.<br>Бүгенге көндә Тукай районының Зур Шилнә авылында гомер кичерәләр. | Бер тамчы җәй: шигырьләр / кереш сүз Р. Бәшәр. − Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2006.<br>Яшәү көче: шигырьләр / кереш сүз белән Г. Шаһи. − Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2008.<br>Күңел шәмем язны көтә: шигырьләр / кереш сүз Р. Бәшәр. − Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2010.<br>Ялгыз бүре: повесть. − Алабуга: «Андерсен», 2012.<br>Күзге тәлгәшләр: шигырьләр. − Яр Чаллы: «Диамант», 2012. |
| **32** | **Мәхмүт ИСМӘГЫЙЛОВ**  | Мәхмүт Хөсәен улы Исмәгыйлов 1950 елның 1 мартында Татарстан Республикасының Кукмара районы Мәмәшир авылында колхозчы гаиләсендә туа. Дүрт еллык белемне туган авылында ала. Аннан 1967 елда, көмеш медаль белән, Мәчкәрә урта мәктәбен тәмамлый. Урта белемле Мәхмүт хезмәт юлын Нократ Аланы (Вятская Поляна) машина төзелеше заводында фрезерчы булып башлап җибәрә.1969-1971 елларда армия сафында хезмәт итә.<br>1977 елда Чаллы шәһәренә килә. 1981 елда читтән торып Мари Политехника институтының машиналар төзү технологиясе факультетын тәмамлый.<br>Яшьтән үк шигырьләр яза. Аның «Җырлыйм дуслар сезнең өчен», «Өметеңне өзмә», «Сөям дип әйтер идем»дигән шигырь сүзләренә Таһир Хәмитов көйләр язган. Үзенең бөтен көчен, тырышлыгын, сабырлыгын җыеп, яраткан, күңеле теләгән хезмәт – рәссам сәнгате белән шөгыльләнә. 1<br>1994 елдан Татарстан рәссамнар берлеге әгъзасы. 2001 елда «Алтын йөрәкле» кеше исеменә лаек. | Әйтер сүзләр калган әле: шигырьләр / кереш сүз белән Г.Шаһи, Р.Хәмидуллина. – Казан: “Милли китап” нәшр., 2017. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **33** | **Таһир ИСМӘГЫЙЛОВ**<br> | Таһир Габдрахман улы Исмәгыйлов 1955 елның 26 декабрендә Татарстан Республикасының Кукмара районы Ташлы-Елга авылында туа. Кәркәүч урта мәктәбен тәмамлагач, Ярославаль шәһәрендәге хәрби-финанс училищесында белем ала. Биш ел Приморье өлкәскендә, унбер ел Украинада хәрби икътисад вазифаларын башкара. Киев сәүдә-икътисад институтын тәмамлый. СССР таркалгач, гаиләсе белән Яр Чаллы шәһәренә кайталар. Шәһәрнең хәрби комиссариан бүлегендә хезмәт итә. Хәрби хезмәтен тутырып, 45 яшендә, подполковник дәрәҗәсендә запаска чыга һәм шунда ук ДОСААФ автомәктәбенә җитәкче итеп алына. Россия Оборона министрының махсус боерыгы нигезендә, полковник дәрәҗәсе бирелә.<br>Таһир Габдрахман улы – 2015 елдан бирле «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. | Гармун теле: шигырьләр, истәлекләр. – Яр Чаллы: Җаваплылыгы чикле “Взаимная помощь” җәмгыяте. – 2015. |
| **34** | **Ринат КАДЫЙРОВ**<br> | Ринат Хәләфетдин улы Кадыйров 1951 елның 23 сентябрендә Казан шәһәрендә туган. Балачак һәм яшьлек еллары Кукмара районы Тәмәй авылында уза.<br>Ринат Хәләфетдин улы шигъри җанлы. 2000 елдан бирле «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри.<br>Бүгенге көндә КАМАЗның пресс-рам заводында бюро башлыгы булып эшли. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **35** | **Зифа КАДЫРОВА**<br> | Зифа Әбделвәли кызы Кадырова 1958 елның 7 октябрендә Башкортостан Республикасының Учалы районы Ахун авылында туа. 1978 елда Чаллы шәһәренә килеп, төзелештә эшли. Сайлаган һөнәренә тугры калып, бүгенге көнгә кадәр авыр физик хезмәттә үзенең беләк һәм рух ныклыгын сыный.<br>Бик күп еллар төзелештә эшли. Бер дә көтмәгәндә, үзенең өч китабы белән бик күп китап укучыларның мәхәббәтен яулап, әдәбият мәйданына Зифа Кадырова килеп керде.<br>Зифа Кадырова бик еш кына түбәндәге монологны кабатларга ярата: «Безнең өй тәрәзәсе гүзәллекнең күзенә карап тора, соклангыч күренеш, илле метрдан тау бите каенлык башланып китә. Бала чагымнан ук шул каенлыктан, иртән сыер савып, көтү куу белән, бер стакан каен җиләге | Язмыш сынавы: повесть.− Яр Чаллы, 2008.<br>Сагынырсың – мин булмам: повесть.− Яр Чаллы, 2008.<br>Көтеп узган гомер: повесть. − Казан, 2009.<br>Сагынырсың – мин булмам: повесть. – Казан, 2009.<br>Бәхеткә юл кайдан?: повесть. – Казан, 2013.<br>Сумбуль: повесть. – Казан, 2012. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | җыеп төшәм. Минут та тик тормас шук, җитез кыз идем. Җәй, көз, яз айларына да карамый тауларда йөрергә яраттым. Кайда нинди чәчәк, җиләк, чия үскәнен мин бик яхшы белә идем. Шул тауларда хыялланып үскән бала мин». | Синсез килгән язлар: повесть. – Казан: «Идел-Пресс» полиграфия-нәшр., 2015. |
| **36** | **Мансур КАШАПОВ (1922-2004)**  | Мансур Кашап улы Кашапов 1922 елның 22 декабрендә Яр Чаллы шәһәрендә туган. Махсус урта белем алгач, лаборант булып эшли. 1941 елда Бөек Ватан сугышына алына. Чехословакиядә партизаннар отрядында сугыша. 1945-1946 елларда Австрия һәм Венгриянең хәрәкәттәге армиясендә шофер булып хезмәт итә. 1954-1960 елларда чирәм җирләрдә тракторист булып эшли, ә аннан – Чаллы. Мансур Кашапов барлык тормышын үзешчән сәнгать театры белән бәйли. 1938 елдан драмтүгәрәк әгъзасы. Сугыштан соң драма коллективының штаттан тыш сәнгать җитәкчесе, ә 1960 елда Чаллы халык театрының режиссеры итеп билгеләнә. Шигырьләр, драма әсәрләре яза, шулай ук аның тарафыннан тәрҗемә ителгән пьесалар халык театры сәхнәсендә уйнала.<br>Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, ТАССР һәм РСФСР Югары Советлары президиумнарының мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре», «КАМАЗ төзелеше ударнигы» исемнәренә лаек була.<br>Мансур Кашапов 2004 елның 29 июнендә вафат булды. | Кара язмыш: повесть. – Яр Чаллы: «Яр Чаллы» типографиясе дәүләт унитар предприятиесе, 2002. |
| **37** | **Равил ЛОТФУЛЛИН**  | Равил Лотфуллин 1940 елда Татарстан Республикасының Арча районы Яңа Кенәр авылында туган. Казан дәүләт университетын тәмамлый. Чаллы шәһәрендә КАМАЗ төзелә башлаганнан бирле КамГЭСэнергострой берләшмәсендә төзелештә эшли.<br>1976-1979 елларда «Ләйсән» берләшмәсен җитәкли. 1979 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Яшьлегем Чаллы» күмәк җыентыгының төзүчесе. Ул әдәбиятка бирелгәнлеге белән каләмдәшләре арасында хөрмәт казана. Яңа каләм тибрәтүче бик күпләр иҗатына үз бәясен биргән автор.<br>Фаҗигале үлем вакытыннан алда арабыздан алып китте. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **38** | **Рифкать МАННАПОВ**<br> | Рифкать Габделгазиз улы Маннапов 1953 елның 8 октябрендә Татарстан Республикасының Апас районы Чүри-Бураш авылында туа.<br>Туган авылында сигезьеллык, 1971 елда Апас урта мәктәбен тәмамлый.<br>1974-1979 елларда Казан дәүләт ветеринария институтында укый.<br>1981 елдан Чаллы шәһәрендә яши.<br>Рифкать Маннапов – 2010 елдан Чаллы Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. | Әтием васыяте: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2011.<br>Атлантида: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2012.<br>Туган илләргә җитми: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2013.<br>Зәңгәр чәчәкләр: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2015.<br>Серле дөнья: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2016. |
| **39** | **Хәнәфи МАННАПОВ** | Хәнәфи Гали улы Маннапов 1909 елның көзендә туа. Татарстан Республикасының Мамадыш районы егете. Хезмәт эшчәнлеген шахтада башлап җибәрә. Шул елларда үзе эшләгән коллективта татар телендә газета чыгара. Хәнәфи Гали улы Бөек Ватан сугышында катнаша. Ул сугышта хәрби журналист була. Сугышта татар егетләрен бергә туплый, алар турында яза, газетада бастырып чыгара. Һәрбер басылып чыккан язма авторының адресын алып, газеталарны туганнарына җибәрә торган була. Бу эшләр кеше кушуы буенча түгел, үз йөрәген тыңлап эшләнә.<br>Инде сугыш бетеп, «Коммунизм байрагы»н җитәкләгән елларда ул газета каршына яшь каләм тибрәтүчеләрне җыя. «Коммунизм байрагы» газетасы каршында ул туплаган каләм осталары 1963 елда «Ләйсән» әдәби-сәнгать берләшмәсе булып оешалар. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **40** | **Миркадәм МАТШИН (1928-2002)**<br> | Миркадәм Әмин улы Матшин 1928 елның 4 ноябрендә Татарстан Республикасының Мамадыш районы Көек-Ерыкса (Комазан Көеге диеп тә йөртәләр) авылында туган. 1936 елны укырга кереп, авыл мәктәбендә җиде классны белем ала һәм Мамадыш педучилищесына укырга керә. Әмма өченче курсны тәмамлагач ук, 1947 елда укытучылык эшен башлап җибәрә. Ул башта туган авылы мәктәбендә башлангыч класслар укытучысы, аннары авыл клубы мөдире булып эшли. Яшьләр өчен төрле түгәрәкләр оештырып, берсеннән-берсе кызыклы стена газеталары чыгара. Тырыш егетне комсомол эшенә чакырып, Мамадыш райкомының бүлек мөдире итеп раслыйлар. Шул елларда каләм тибрәтә башлый, аның язмалары газета битләрендә күренеп килә. Бер үк вакытта читтән торып Чистай педагогия училищесын тәмамлый. | Гөрләвекләр кайда яши?: балалар өчен хикәя һәм әкиятләр. – Яр Чаллы: «КАМАЗ»нәшр., 1986.<br>Сәртүш: балалар өчен хикәя һәм әкиятләр. – Яр Чаллы: «КАМАЗ» нәшр., 1998.<br>Солдатмы, генералмы?: балалар өчен хикәя һәм әкиятләр. – Яр Чаллы, 1998.<br>Мәзәкле сәяхәт: балалар өчен хикәя һәм әкиятләр. – Яр Чаллы: «КАМАЗ»нәшр., 1999. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Миркадәм Әмин улы 1966 елда гаиләсе белән Яр Чаллыга күчеп килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Чаллы шәһәрендә яши.<br>Ул Россия инвалидлар җәмгыятенең Почетлы члены, алты дәүләт медальләре һәм «КАМАЗ төзелеше ударнигы» билгесе белән бүләкләнә.<br>2002 елның 28 февралендә вафат булды. | |
| **41** | **Әгъния МИННЕБАЕВА**<br> | Әгъния Мөҗәһит кызы Сабирова – Миннебаева 1957 елның 8 мартында Башкортостанның Илеш районы Сеңрән авылында туган.<br>Урта мәктәпне тәмамлагач, кыз Уфа каласына юл тота һәм азык-төлек сәнәгате техникумына укырга керә. Әлеге уку йортын 4-5 билгеләренә генә бетергән Әгъния Воткинскидагы кондитер фабрикасында технолог булып эшли башлый. Тик ул сайлаган һөнәреннән тәм табалмый, хыялы кайдадыр чакыра. Абыйларына кунакка килгәч, Чаллы каласындагы әдәби мохитнең киңлеген тою аның күңелен кузгата һәм ул Чаллыга күченеп килә. Яшь шагыйрә «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә йөри башлый.<br>Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. Хәзерге көндә «Яңа гасыр» радиосының Чаллы төбәгендәге үзхәбәрчесе булып эшли. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **42** | **Рафис МОГЫЙНОВ (1948-2013)**<br> | Рафис Әмерсәяф улы Могыйнов 1948 елның 15 апрелендә Татарстан Республикасының Сарман районы Мортышбаш авылында укытучылар гаиләсендә туган.<br>1966 елны Сарман урта мәктәбен тәмамлый. Район газетасында корректор, әдәби сотрудник булып эшли.<br>1967 елда армиягә алына. Татарстаннан читтә яшәсә дә, Р. Могыйнов туган ягы белән элемтәләрне өзми. Аның армиядә хезмәт итүче якташларыбыз турында язган очерклары, зарисовкалары, мәкаләләре, фотоинформацияләре даими рәвештә газета, журналларда дөнья күрә. Рафис Могыйнов шигырьләр, җыр текстлары, юморескалар, хикәяләр дә иҗат итә.<br>1992 елда Рафис Могыйнов, армия хезмәтен тәмамлап запаска чыга, Чаллы шәһәренә кайта һәм «Шәһри Чаллы» газетасына баш мөхәррир урынбасары булып эшкә урнаша. Биредә, үзенең кабул итү бүлмәсендә, ул елларда Чаллыда гомер итүче Советлар Союзы | Сарман. Сарманово: [краеведческий сборник]. – Чита: Воениздат, 1987.<br>Русско-татарский словарь военных терминов: [научное издание]. – Казань, 2000.<br>Бөек Җиңү ачысы: [татар генераллары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары турында хатирәләр]. – Яр Чаллы, 2005.<br>Тимер ташкынга каршы: [публицистик язмалар]. – Яр Чаллы, 2008.<br>Сез ки газизләр... – Тоскуем по вас...: [Татарстан егетләренең Бөек |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Каһарманы Илдар Маннан улы Маннановның Сугышчан Дан музееен оештыра һәм аны Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре белән очрашулар, матбугат конференцияләре уздыру урынына әвеределдерә.<br>Рафис Әмерсәяф улы Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1999), Татарстан Республикасының Журналистлар берлеге әгъзасы (1974).<br>2013 елның 8 июлендә каты авырудан вафат булды. | Ватан сугышы фронтларыннан язган хатлары]. – Яр Чаллы, 2010.<br>Порохом пахнущие строки... – Хатларында дары исе...: [фронтовые письма татарстанцев]. – Набережные Челны, 2011.<br>Тимер ташкынга каршы: Илдар повесть. – Казан, 2011. |
| **43** | **Равил МОСТАФИН**<br> | Равил Гарәф улы Мостафин 1956 елның 16 декабрендә Татарстан Республикасының Мамадыш районы Түбән Сөн авылында туа. Туган авылында сигезьеллык мәктәп (1972), аннан күрше Үсәли урта мәктәбен тәмамлый. 1974-76 елларда армия сафларында хезмәт итә, 1990 -1993 елларда Казан дәүләт университетының татар теле әдәбияты һәм шәрыкъ телләр бүлегендә читтән торып укый. 1976 елны тормыш юлын КАМАЗ – Чаллы төзелеше белән бәйли. 1976 елдан бирле «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри.<br>1995 елдан алып бүгенге көнгә кадәр Төмән өлкәсе Ямбург поселогында Газпром оешмасында вахта методы белән хезмәт куя. Өйләнгән, кыз үстерә. | Җирсү: шигырьләр . − Яр Чаллы, 2000.<br>Сиңа илткән юл: шигырьләр. − Яр Чаллы, 2001.<br>Сөялдем каеннарга: шигырьләр. − Яр Чаллы, 2004.<br>Благодарен судьбе!: стихи. − Казань: Изд., «Паритет», 2006.<br>Тормыш дәрьясын кичкәндә: шигырьләр. – Казан, 2012.<br>Уйланулар. – Яр Чаллы, 2015. |
| **44** | **Рәфкать МУЛЛИН (1947-2013)**<br> | Рәфкать Нурулла улы Муллин 1947 елның 5 июлендә Татарстан Республикасының Түбән Кама районы Рәфкать Нурулла улы Иштирәк авылында туа. Туган авылында сигезьеллык мәктәп тәмамлап, Рәфкать укуын башта Сүбәләк авылында, аннары Түбән Кама шәһәренең беренче урта мәктәбендә дәвам итә. Аннан соң Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә.<br>Яр Чаллы каласында 1990-1994 елларда М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназияне җитәкли. Аннан соң гаиләсе белән Түбән Кама шәһәренә күчә.<br>Рәфкать Муллин эшләгән җирдә һәрвакыт яңалык алып килә. Ул 1987 елдан РСФСРның мәгариф эше отличнигы, шагыйрь җанлы педагог кыю фикерләр, зур өметләр белән яши.<br>Рәфкать Нурулла улы 2013 елның 13 мартында каты авырудан соң вафат була. | Изге чишмәләр: шигырьләр. – Түбән Кама нәшр., 1997.<br>Дусларымны барлыйм: истәлекләр, шигырьләр. – Казан: «Сүз» нәшр., 2007. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **45** | **Хәмит МӨХӘММӘТШИН**<br> | Хәмит Нәҗип улы Мөхәммәтшин 1931 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасының Тәкәнеш (хәзерге Мамадыш) районы Түбән Тәкәнеш авылында туа. Туган авылында урта мәктәпне, аннан Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Яр Чаллыда «КАМАЗ» төзелеше җәелгәч, Чаллы зонасына «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе итеп җибәрелә. Беренче көннән үк төзелешнең кайнар сулышын газета укучыларга җиткерә. СССР Журналистлар союзының Мактау грамотасына (1972) лаек була. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1983), Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданины (2002), Татарстан журналистлар берлеге әгъзасы (1965). «Хәтердә ул еллар», «Җир фәрештәсе» «Заслуженные люди Тукаевского района», «Чулман дулкыннары ни сөйли?» (Й. В. Кормашев белән берлектә) дигән китаплар авторы.<br>Бүгенге көндә Чаллы шәһәрендә яши. | Заслуженные люди Тукаевского района. Издание I / составитель Х. Н. Мухаметшин. – Наб.Челны: ГУП «Набережночелнинская типография», 2003.<br>Заслуженные люди Тукаевского района. Издание II / составитель Х. Н. Мухаметшин. – Наб.Челны, 2005.<br>Заслуженные люди Тукаевского района. Издание III / составитель Х. Н. Мухаметшин. – Наб.Челны, 2005. |
| **46** | **Рәзинә НАСЫЙБУЛЛИНА**<br> | Рәзинә Мәсгут кызы Насыйбуллина-Закирова 1953 елның 14 мартында Татарстан Республикасының Минзәлә районы Чебенле (Тойгузино) авылында туа. Хуҗамәт урта мәктәбен, аннан Казан дәүләт университетының татар теле бүлеген тәмамлый.<br>Рәзинә 8 нче мәктәптә татар теле укытучы, «Камские зори» газетасында тәрҗемәче, корректор вазыйфаларын башкара. Ә 1981 елда Тукай районы газетасы «Якты юл» га эшкә килә. Биредә корректор, аннан тәрҗемәче, дистә елга якын редактор урынбасары булып эшли. Шул елларда үзе дә газетага материаллар яза башлый.<br>2001 елда Рәзинә Насыйбуллина Чаллы телевидениесенә эшкә чакырыла. 2007 елдан директор урынбасары вазыйфаларын башкара. Шигырьләр, хикәяләр яза.<br>Рәзинә Мәсгут кызы журналистикада 30 ел хезмәт куя.<br>Татарстан Республикасы журналистлар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. | Әрем исе: шигырьләр. – Чаллы: «Яр Чаллы типографиясе» ачык акционерлык җәмгыяте, 2005. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **47** | **Кадрия НАИЛ**  | Кадрия Наил кызы Хәбибуллина-Хәлилова (Кадрия Наил) 1951 елның 1 августында Татарстан Республикасының Актаныш районы Зөбәер авылында туа. Мөслим районы Симәк авыл мәктәбенең 8 сыйныфын тәмамлый. 1966-1969 елларда Бөгелмә медицина училищесында белем ала. Аны тәмамлагач Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында урнашкан «Балалар санатоние»сендә хезмәт юлын башлап җибәрә. Аннан Казан, Түбән Кама, Алабуга шәһәрләрендә шәфкать туташы булып эшли.<br>Әтисе − Наил Габидин улы (1925-2008) агроном һәм бик күп еллар колхоз председателе булып эшли. «Ленин ордены» кавалеры була. Әнисе − Зәмфирә Сафуан кызы (1928-2012) 40 елдан артык укытучы булып хезмәт итә.<br>Кадрия Наилнең шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә бик еш басылып килә.<br>2008 елны «Агыла күңелем моңнары» дигән тәүге шигъри җыентыгы дөнья күрде. Бүгенге көндә сигез китап авторы, җырлары тупланган компакт дискта чыгарды.<br>2008 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. | Агыла күңелем моңнары: шигырьләр. − Яр Чаллы: 2008.<br>Йөрәк куша җырлап яшәргә. − Яр Чаллы: 2009.<br>Күңел язым чәчәк атканда. − Яр Чаллы: 2010.<br>Көзге моңнар: шигырьләр, җырлар. − Алабуга: 2011.<br>Әй, кайтасы иде яшьлеккә: аудиокассета. – Яр Чаллы, 2010.<br>Оч күңелем: җырлар, ноталар. − Алабуга: 2011.<br>Яшьлек язларымны юксынам: шигырьләр. − Алабуга: 2012.<br>Балачак иртәләре: балалар өчен шигырьләр. − Алабуга: 2012.<br>Их, кайтасы иде яшьлеккә: шигырьләр. − Алабуга: 2012.<br>Бәхет нуры: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2016. |
| **48** | **Галинур НӘБИЕВ (1951-1993)**  | Галинур Кадхыйнур улы Нәбиев 1951 елның 23 гыйнварында Башкортостан Республикасының Бакалы районындагы Яңа Катай авылында туа.<br>1968 елда шушы авылда урта мәктәпне тәмамлый. 1970-1972 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.<br>1972 нче елдан «Камгэсэнергострой»ның төзелешне механикалаштыру идарәсендә экскаватор машинисты булып эшли.<br>1993 елның маенда фаҗигале төстә вафат була. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **49** | **Заһидә НӘБИУЛЛИНА**<br> | Заһидә Мотык кызы Нәбиуллина 1938 елның 23 июнендә Ютазы районы Кәрәкәшле авылында туган. Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый.<br>1963-1976 елларда «Коммунизм байрагы» газетасында тәрҗемәче вазыйфаларын башкара. 1976-1990 елларда «Якты юл» газетасында хатлар бүлеге мөдире, 2001 елдан газетаның мөхәррир урынбасары булып хезмәт итә.<br>«Ләйсән» әдәби берләшмәнең беренче көннәреннән үк даими сәркатибе була, ул һәр утырышның беркетмәсен язып бара.<br>«Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре», «КАМАЗ төзелеше ударнигы». | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **50** | **Наил НӘҖМИ (1958-2007)**<br> | Наил Галимҗан улы Нәҗмиев (Наил Нәҗми) 1958 елның 8 гыйнварында Татарстанның Нурлат районы Берлек авылында туа. Күрше Елаур авылында урта мәктәпне тәмамлый.<br>1988 елдан бирле Чаллы каласында яши. Өйләнгән, өч баласы бар. Күп еллар шәһәр торак идарәсендә слесар-монтажчы булып эшләде.<br>Наил Нәҗми яшь вакыттан шигырләр яза. Иҗат җимешләре шәһәр матбугатында басылып килде. 2007 елда вафат булды. | Галәм сагышы: шигырьләр /. – Яр Чаллы: 2001.<br>Күңел көзгесе: шигырьләр / Н. Нәҗми. – Яр Чаллы: 2004.<br>Соңгы җырым: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2006. |
| **51** | **Зөлфия НИГМАНОВА**<br> | Зөлфия Фатыйх кызы Нигманова 1947 елның 20 июлендә Татарстан Республикасының Чүпрәле районы Яңа Ишле авылында туа. Туган ягында урта белем ала.<br>Үсмер елларында Зөлфия «Алга» колхозында терлекчелек фермасында эшли. Башта Ульяновск шәһәрендә, аннан ундүрт ел Башкортостанның Стерлетамак шәһәрендә хезмәт итә. 1979 елдан Чаллы каласындагы гигант төзелешенә килә. «Госстрах» агенты була. Шәһәребездә 25 ел хезмәт итеп, лаеклы ялга чыга.<br>Ятимлектә үсә Зөлфия моңлы булып, шушы зар-моңнары тора-бара аның күңелендә башкаларга сөйләрлек дәрәҗәдә бөреләнгән һәм алар шигырь рәвешендә дөньяга шытып чыкканчы күп сулар аккан әле. Олыгаеп җиткәч, Зөлфиянең калебендә яралган хисләре җитлеккән шигырьләр булып ак кәгазь битләрендә мәйдан сорый башлаганнар.«Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри (1999) | Юкә балы: шигырьләр. − Яр Чаллы: 2003.<br>Яшьлегем карлыгачы: шигырьләр / кереш сүз Р. Бәшәр. − Яр Чаллы, 2004.<br>Якты теләк: шигырьләр. − Яр Чаллы, 2006.<br>Сандугачлы алмагач: шигырьләр / кереш сүз Р. Бәшәр. − Яр Чаллы, 2008.<br>Алмагачлар коелганда: шигырьләр / З. Нигманова; кереш сүз Р. Бәшәр. − Яр Чаллы, 2012 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **52** | **Фәнис НУРЕТДИНОВ**<br> | Фәнис Бари улы Нуретдинов 1952 елның 19 февралендә Татарстан Республикасының Чирмешән районы Иске Кади авылында туа. 1970 елда туган авылында урта мәктәп тәмамлый.<br>1970-1972 елларда армия сафларында хезмәт итә. 1973 елны комсомол оешмасы юлламасы белән Чаллыга, КАМАЗ төзелешенә эшкә килә. Алты ел Автозавод төзелешендә эретеп ябыштыручы булып, аннан ун ел дәвамында Тукай кошчылык фабрикасында эшли. Читтән торып Минзәлә совхоз-техникумын тәмамлый, агроном белгечлеге ала. Берара Фәнис Минзәлә район газетасында штаттан тыш хәбәрче вазыйфасын башкара. Шул вакытта үзе дә сизмичә язу эшенә тартыла. | Галимҗан абый хатирәләре: истәлекләр. – Чаллы. – 2006.<br>Шаян хәлләр: мәзәкләр /кереш сүз белән Ф. Хәйдәрова. – Чаллы. – 2006.<br>Уены-чыны бергә: мәзәкләр / кереш сүз белән Л. Яруллина. – Чаллы. – 2007.<br>Көлегез дуслар: мәзәкләр / мөхәррир Р. Бәшәр. – Чаллы. – 2007. |
| **53** | **Идрис РЫСКУЖИН (1922-2000)**<br> | Идрис Юныс улы Рыскужин 1922 елда Башкортостан Республикасының Әбҗәлил районында Урал елгасы ярында урнашкан бәләкәй генә Үтәгән авылында туа. Аңа яшьтән үк дөньяның әчесен-төчесен татырга туры килә. Бөек Ватан сугышында разведка взводы белән җитәкчелек итә. Тумышыннан математикага һәвәс Идрис Рыскужин тыныч елларда төзелеш оешмаларында экономист булып эшли, галимнәрнең фәнни эшләрен башкорт теленә тәрҗемә итә, үзе дә төрле фәнни темаларга мәкаләләр язып матбугатта бастыра.<br>Идрис Рыскужин Бөек Ватан сугышы ветераны, «Кызыл йолдыз», «I дәрәҗә Ватан сугышы» орденнары кавалеры, бик күп медальләр белән бүләкләнә. 1972 елда «КАМАЗ» төзелеше башлангач гаиләсе белән Яр Чаллы каласына килә. Лаеклы ялга чыкканчы КамГЭСэнергострой берләшмәсендә экономист булып эшли. Аның әсәрләре республика һәм шәһәребез вакытлы матбугат битләрендә еш басыла. «Разведчик язмалары» дип исемләнгән әсәре Башкортостанның «Агыйдел» журналында басылып чыга. Яр Чаллы шәһәрендәге «Шоңкар» милли-мәдәни оешмасының әгъзасы Идрис Юныс улы матур итеп мандолинада уйный, шигырьләр яза иде.<br>Идрис Рыскужин 2000 елда вафат була. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **54** | **Ирек САДЫЙКОВ**<br> | Ирек Кирам улы Садыйков 1957 елның 1 гыйнварында Татарстан Республикасының Актаныш районы Иске Аймаш авылында туа. Туган авылында ике сыйныф белем ала, аннан соң Садыйковлар гаиләсе Әгерҗе районы Исенбай авылына күчеп килә. Авыл мәктәбендә сигезенче класста укыган вакытта әтиләре үлеп китә. Шул сәбәпле күп балалы Садыйковлар гаиләсе Чаллыга күчеп кайталар. Аңа 1974-1975 елларда 9-10 сыйныфларны шәһәребезнең Мулланур Вахитов исемендәге мәктәбендә тәмамлый. Әтисез калгач ишле гаилә баласы Ireккә шофер һөнәрен үзләштереп эшли башлый.<br>Ирек Садыйков яшьтән кулына каләм ала. 1992 елда Ирек Казан шәһәренә эшкә килә. Ун еллар тирәсе «Шәһри Казан» газетасында хезмәт итә. Казанда яшәгән ун җиде ел вакытын: Гомеремнең иң матур, бәхетле чоры», – диеп искә ала.<br>Ирек Кирам улы бүгенге көндә Яр Чаллы шәһәрендә яши. | Хыянәт: хикәяләр / И. Кирам (Садыйков). Чаллы: «КАМАЗ» кит. нәшр., 1992. |
| **55** | **Нәсимә САДЫЙКОВА**<br> | Нәсимә Исхак кызы Садыйкова 1952 елның 11 октябрендә Татарстан Республикасының Чистай районы Исләй авылында туа. 1960 елда туган авылы сигезьеллык мәктәбенә укырга керә. Аны 1968 елда тәмамлап,. 1969-1970 елларда Каргалы урта мәктәбендә белем ала.<br>Беренче мәкаләләре «Яшь ленинчы» газетасында 1965 елда басылып чыга. 1970 елның октябренда, комсомол путевкасы белән КАМАЗ төзелешенә килә. 1970-1973 елларда «Промстрой» төзелеш идарәсендә штукатур-маляр булып эшли.<br>1973 елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә.<br>1980 елда Әлки район газетасына эшкә килә. Башта корреспондент 1982 елдан редактор урынбасары вазыйфаларын башкара. 1982 елда «Татарстан яшьләре»газетасында, бүлек мөдире булып эшли башлый. 1992 елда гаиләсе белән Яр Чаллыга күчеп кайта. «Шәһри Чаллы» («Чулман-Идел») газетасы редакциясендә хатлар бүлегендә корреспондент булып эшли байлый. 1993 елда «Шәһри Чаллы» газетасының «Көмеш кыңгырау» кушымтасы чыга башлый, һәм Нәсимә Садыйкова мөхәррир итеп билгеләнә.<br>2003 елдан Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Үз һөнәренә тугрылык саклап «Татар мөселман балалары өчен «Фатиха» китап-календарен» чыгара. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **56** | **Рәфыйк САФИН**<br> | Рәфыйк Гарәф улы Сафин 1963 елның 14 сентябрендә Татарстан Республикасының Аксубай районы Шәрбән авылында туа. Туган авылында сигезьеллык, ә күрше Дума мәктәбендә урта белем ала. 1981 елда Яр Чаллы каласына килә. 64 нче һөнәри училищены тәмамлый. 1982-1984 елларда Мәскәү өлкәсендә Армия сафларында хезмәт итеп, янәдән Чаллы шәһәренә кайта. Мәскәү электромеханика техникумының кичке бүлеген тәмамлый. 2000 еллардан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри.<br>Өйләнгән ике бала үстерә. Бүгенге көндә КАМАЗның пресс-рам заводында электр җиһазларын төзәтүче булып эшли. | Кайнар чәчәк: шигырьләр. – Чаллы. – 2008.<br>Кайнар сулыш: шигырьләр. – Чаллы. – 2013. |
| **57** | **Серафима САФИНА**<br> | Серафима Кәниф кызы Сафина 1960 елның 20 маенда Башкортостан Республикасының Калтасы районы Күгәрчен авылында туа. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлый. 1992 елда Башкорт дәүләт университетының филология факультетында укый, күп еллар укытучы булып эшли.<br>Серафима Сафина шигърияткә кече яшьтән гашыйк. Бер бәйләм шигырьләре «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009) исемле күмәк җыентыкта дөнья күрделәр.<br>КАМАЗда хезмәт юлын кранчы булып эшләүдән башлый. «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | Күгәрченем: шигырьләр. – Яр Чаллы, – 2014. |
| **58** | **Зөфәр СӘГЫЙТОВ**<br> | Зөфәр Ярулла улы Сәгыйтов 1929 елның 12 августында Татарстан Республикасының Чаллы (хәзерге Тукай) районы Биклән авылында туган. Алабуга мәдәният училищесының дирижерлык, соңрак Казан педагогия институтының музыка факультетларын тәмамлый. Музыкаль сәләте – эти-әнисеннән. Дүрт яшеннән тальянда, саратский гармунда уйный. Бөек Ватан сугышы елларында Чаллыга күчеп килгәч, үсмер чагында тынлы оркестрда уйнаган. Армиядә инструменталь ансамбль оештырган.<br>1970 елларда көйләре кала төзергә килгән яшьләрнең күңел юаткычы, дәрт чишмәсе була. Чаллы каласында татар җырын дүрт тавышка башкаручы беренче хор оештыручы да ул. Бөек Җиңүнең 40 | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | еллыгы уңаеннан, бөтенсоюз патриотик җырлар фестиваль-конкурсы игълан ителгәч, Зөфәр Ярулла улы «Мәңгелек ут» (Р. Хисами сүз.) һәм «Без тынычлык сакчылары» (Н. Дәүли сүз.) дигән җырларын язып, конкурска җибәрә. Җырлары икесе дә жюри тарафыннан югары бәяләнә һәм фестиваль программасына кертелә. Фестивальне Зөфәр Сәгыйтов җитәкчелек иткән сәүдә-кулинария училищесының 30 кешелек хоры башкаруында шушы ике җыр белән ачып җибәрәләр.<br>Хәзерге көндә лаеклы ялда. Чаллы шәһәрендә яши. | |
| 59 | **Тәнзилә СӘГЫЙТОВА**<br> | Тәнзилә Сәгыйтова Татарстан Республикасының Арча районында туган.<br>1980 еллар башында шигырьләре республика һәм шәһәребез вакытлы матбугат битләрендә еш басыла. Бер бәйләм шигырьләре «Яшьлегем Чаллы» (1979) «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009) исемле күмәк җыентыкларда дөнья күрделәр | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| 60 | **Гөлсирень СӘГЪДИЕВА**<br> | Гөлсирень Әгъзам кызы Сәгъдиева 1989 елның 23 мартында Татарстан Республикасының Әлки районы Базарлы Матак авылында туа. Туган авылында тугызынчы сыйныфны тәмамлый. Аннан Базарлы Матак 95 нче санлы һөнәр училищесында пешекче һөнәре белгечлеген ала.<br>2006 елда Республика күләмендә оештырылган «Иделем акчарлагы» бәйгесендә катнашып җиңү яулый.<br>2009 елдан Яр Чаллы шәһәрендә яши.<br>Чаллы Язучылар оешмасы каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 2009 елдан бирле йөри. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **61** | **Шәрига ТАҺИРОВА (1922-2008)**  | Шәрига Гази кызы Таһирова 1922 елның 28 октябрендә Татарстан Республикасының Чирмешән районы Кара Чишмә авылында туа. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлап, Бөгелмә педагогия училищесында укуын дәвам итә. Читтән торып Казан дәүләт педагогия институтында югары педагогик белем ала.<br>1979 елда Таһировалар гаиләсе Чаллы шәһәренә күчеп киләләр. Шәрига Таһирова шәһәрнең 8 нче урта мәктәбендә татар теле укыта.<br>Шәрига Гази кызының татар халкының әдәбият, мәдәниятен үстерүгә салган эзе тирән.<br>Шәрига Таһирова 2008 елның 31декабрендә вафат була. | Җырларым: шигырьләр. – Яр.Чаллы. – 1998.<br>Каеннарны сөям: шигырьләр. – Яр.Чаллы. – 2008. |
| **62** | **Флүрә ТАЛИПОВА**  | Флүрә Нәфыйк кызы Талипова – Коләхмәтова 1968 елның 10 февралендә Башкортостан Республикасының Салават районы Лаклы авылында туа. Туган авылында урта мәктәп тәмамлый.<br>1985-1990 елларда Стәрлетамак дәүләт педагогия институтының филология факультетында белем ала. Хезмәт юлын туган авылы урта мәктәбендә тәрбия-оештыру эшләре буенча мөдир булып башлап җибәрә.<br>1992 елдан Яр Чаллы каласында яши. 2008 елдан алып бүгенге көнгә кадәр «Эврика» шәһәр мәдәният үзәгендә артист-вокалист булып эшли. | Әдәби Чаллы: / [төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. |
| **63** | **Мөслах ТАҖИЕВ (1938-1974)**  | Мөслахетдин Зыятдин улы Таҗиев (Мөслах Таҗи) 1938 елның 8 августында Татарстан Республикасының Түбән Кама (элеккеге Ширәмәт) районы Ташлык авылында колхозчы гаиләсендә туа. Сугыш еллары буыны кичергән барлык авырлыкларны күрә. Үпкә чире эләктерә. Бу дөньяда бары тик 36 ел яшәп китте шагыйрь.<br>Мөслах Таҗиевның йөрәге 1974 елның 8 август көнендә тибүдән туктый. | Мәхәббәт үзе яз: [шигырь] / М. Таҗиев // Якты юл. – 1983. – 3 дек.<br>Мәхәббәт үзе яз; Минем муза: [шигырьләр] // «Ләйсән» – моңлы бишегебез: Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең күмәк җыентыгы / төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова. – Яр Чаллы, 2009. – Б. 25. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 64 | **Нәсих ТАҖИЕВ**<br> | Нәсих Фатыйх улы Таҗиев 1938 елның 7 августында Татарстан Республикасының Әлки районы Урта Әлки авылында туа. Урта мәктәп, Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. Чаллыдагы татар газеталарында баш редактор булып эшли. Бик күп очерклары, шигырьләре республика газета-журналларында басылып килә.<br>Татар матбугатындагы эшчәнлеге өчен ТР Президентының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. КАМАЗ төзелеше ударнигы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелә. | Кизләү: повесть һәм хикәяләр. – Казан, 2010.<br>Җидегән йолдыз: әдәби очерклар. – Казан, 2004.<br>Баскыч һәм элмәк: мәсәлләр. – Казан, 2006.<br>Соңгы фронтовик: повесть һәм хикәяләр. – Казан, 2010.<br>Кояшлы гөл: шигырьләр һәм мәсәлләр. – Казан, 2013. |
| 65 | **Илсөяр ТИМЕРБАЕВА – МОСТАФИНА**<br> | Илсөяр Әхмәтсафа кызы Мостафина-Тимербаева 1957 елның 1 августында Татарстан Республикасының Мамадыш районы Арташ авылында ишле гаиләдә дөньяга тәүге авазын сала. 1977 нче елдан Чаллы каласында яши. Озак еллар КАМАЗның моторлар заводында, 1989 елдан иҗади коллективларда – Татарстан Язучылар Берлегенең Чаллы бүлегендә, «Ак бүре» киностудиясе, «Аргамак» журналларында эшли. 2001-2011 елларда «Чаллы-ТВ» телерадиокомпаниясенә хезмәт куя.<br>2012 елдан Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы. | |
| 66 | **Гөлсинә ТӨХБӘТУЛЛИНА**<br> | Гөлсинә Гаптелбәр кызы Төхбәтуллина 1960 елның 6 гыйнварында Оренбург өлкәсе Адамовка районы, Джуссинск бистәсендә туа. 1968 елда гаилә Татарстан Республикасының Азнакай районы Югары Стәрле авылына кайтып төпләнә. Шул елны Гөлсинә Гаптелбәр кызы авыл мәктәбенең беренче сыйныфына укырга керә. 1978 елда урта мәктәпне тәмамлап, Казан авыл хуҗалыгы институтына юл тота. 1983 елда икътисадчы дипломы алып, авыл хуҗалыгында эшли башлый. 1987 елда Төхбәтуллиннар гаиләсе Чаллы шәһәренә күченә. Ул. “Татэлектромаш” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятендә икътисадчы булып хезмәт куя. Бүгенге көндә Яр Чаллы йогышлы авырулар хастаханәсе хезмәткәре.<br>2015 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | Сөйлим сезнең хакта...: документаль язма, – Яр Чаллы, 2016. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **67** | **Гөлфия ФӘЙЗРАХМАНОВА**<br> | Гөлфия Шәйхулла кызы Фәйзрахманова 1962 елның 16 мартында Татарстан Республикасының Саба районы Эзмә авылында туа. Туган авылында сигезьеллык, күрше Шәмәрдән поселогында урта мәктәпне тәмамлый. Күңелендә йөрткән балачак хыялының асылына төшенергә теләп, урта белемле кыз авыл мәдәният йортына художество җитәкчесе булып эшкә урнаша. 1980 елда Алабуга мәдәни-агарту техникумының режиссура бүлегенә укырга керә.<br>1985 елда Фәйзрахмановар гаиләсе Яр Чаллы шәһәренә килә. 1993 елдан башлап Гөлфия Ф. Чаллы татар дәүләт драма театры артисткасы булып эшли. Татарстан Республикасының атказанган артисткасы ( 2010).<br>2012 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. | |
| **68** | **Тәзкирә ХАКОВА**<br> | Тәзкирә Хәбинур кызы Хакова-Хәбибуллина 1934 елның 1 октябрендә Башкортостан Республикасының Шаран районы Тугызкыз-Сөнбаш авылында туа. 1942-1949 елларда туган авылында урта мәктәпне тәмамлый. Зирекле авылында сигезенче класста укый.<br>Тәзкирә 63 яшь тулгач шигырьләр, фантастик һәм шаян-көлкеле хикәяләр яза башлый. Беренче шигырь, хикәяләр җыентыгы «Ана йөрәге» дигән исем белән 2003 елда дөнья күрә. Бүгенге көндә Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итә.<br>1994 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. | Ана йөрәге: хикәяләр, балалар шигырьләре. − Яр Чаллы: «КамАЗ» нәшр., 2003.<br>Язмыш дәрьясында: повесть / кереш сүз Р. Гыйззәтуллина, Х. Шәриф. − Яр Чаллы: «Ислам нуры» нәшр., 2009.<br>Ана йөрәге: хикәяләр, шигырьләр / кереш сүз Р. Бәшәр, Ф. Хәйдәрова. − Яр Чаллы: «Ислам нуры» нәшр., 2010. |
| **69** | **Венера ХӘБИБРАХМАНОВА**<br> | Венера Гадел кызы Хәбибрахманова 1941 елда Башкортостанның Яңавыл районындагы Исәнбай авылында туган. Әтисе сугышта һәлак булу сәбәпле, ул әнисенең туган авылы Кальтәүдә үсә, Кальтәү җидееллык мәктәбен тәмамлый. Аннан соң Авыргазыда профтехучилищеда укый. Бакчачы була.<br>1973 елда Чаллыга күчеп килә һәм КАМАЗда төрле эшләрдә эшли. Аның бер бәйләм шигырьләре «Азат хатын», «Казан утлары» журналларында, «Яшьлегем-Чаллы» (1979), «Кызлар җыры» (1984), «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009) исемле кумәк җыентыкларда, ә мөстәкыйль булып бер китабы дөнья күрде.<br>Венера Хәбибрахманова иҗаты гөрләп чәчәк атканда вафат була. | Чишмәләргә килдем: шигырьләр. – Яр Чаллы: «КАМАЗ» нәшр., 1993. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **70** | **Фәйрүзә ХӘЙДӘРОВА – ЖАББАРОВА**  | Фәйрүзә Харис кызы Хәйдәрова – Җаббарова 1960 елның 7 апрелендә Татарстан Республикасының Зәй районы Бура-Киртә авылында дөньяга килә. Авылда сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, күрше Борды авылы мәктәбендә урта белем ала.<br>Фәйрүзә кечкенәдән үк рәсем ясарга ярата, китапларны бик яратып укый. Рәсем ясауга һәвәслеге Фәйрүзәне соңрак Мәскәү сәнгать университетына алып килсә, ә китапка мәхәббәт Яр Чаллы педагогия институтына укырга тарта. Аның очерклары, парчалары, шигырьләре, теге яки бу авторның иҗаты турындагы язмалары газета-журналларда еш басыла.<br>«Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 1997 елдан бирле йөри. | Зәрә тау: очерклар, парчалар, нәсер, әдәби күзәтүләр, шигырьләр / Ф. Хәйдәрова-Җаббарова. – Яр Чаллы. 2003. – 64 б. |
| **71** | **Рәшит ХӘЙРЕТДИНОВ**  | Рәшит Фәррах улы Хәйретдинов 1948 елның 23 августында Татарстан Республикасының Азнакай районы Кәкре Елга авылында туган. Башта авыл урта мәктәбен, ә 1972 елда Казан химия-технология институтын тәмамлап, нефть һәм газ эшкәртү буенча инженер-технолог белгечлеге ала.<br>1995 елда «Ялгыз җайдак» исемле шигырьләр китабы чыга. Иң күп укылган китаплар бәйгесендә республика Милли китапханәсенең II дәрәҗә Дипломы белән бүләкләнә. Шигырьләре үзенең гадилеге, самимилеге, эчкерсезлеге белән җәлеп итә. | Ялгыз җайдак: шигырьләр– Чаллы: «Мәгърифәт» кит. нәшр., 1995. |
| **72** | **Сания ХӘЙРЕТДИНОВА**  | Сания Гыйльмулла кызы Хәйретдинова (Карюкова) 1951 елның 27 гыйнварында Татарстан Республикасының Зәй районы Бура-Киртә авылында туа. Авылда сигезьеллык белем, 9-10 сыйныфларда М. Вахитов исемендәге 2 нче мәктәпне тәмамлый.<br>1972 елдан башлап 30 ел буе «КамГЭСэнергостройның» 1 нче измә-бетон заводында хезмәт итә: измә биреп тору операторы, диспетчер, мастер, цех башлыгы вазыйфаларын башкара. «Мәйдан» журналында хезмәт куя. Ун елдан артык солдат аналары комитеты белән җитәкчелек итә.<br>Хәзерге көндә лаеклы ялда. | Алтын күпер: шигырьләр. – Яр Чаллы, 1999.<br>Гомер-мизгел: шигырьләр / кереш сүз белән Р. Бәшәр. – Яр Чаллы, 2005.<br>Бура-Киртә: «Иң серле, иң изге нигезем»: тарихи. – Казан: 2012. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 73 | **Зәбир ХӘЛИМОВ**  | Зәбир Фәхерлегаян улы Хәлимов 1952 елның 28 апрелендә Татарстанның Актаныш районы Үмәнәй авылында туа. Беренче дүртенче сыйныфларны туган авылында укый, Биш-сигезенче сыйныфларда Адай сигезьеллык мәктәбендә белем ала. Минзәлә педучилищесын, Казан дәүләт университетын тәмамлый. Актаныштa озак еллар эшләп килгән “Агыйдел дулкыннары” иҗат берләшмәсендә Әмирҗан Моталлапов, Хәмит Миңлегалиев, Мөслах Таҗи, Фәйрүзә Мөслимовалар белән шигырьләр анализлаган. Аның иҗат җимешләре “Татарстан яшьләре”, “Игенче даны”, “Көмеш кыңгырау”, “Нур”, Шәһри Чаллы”, “Якты юл”, “Яңарыш” газеталарында, “Фән һәм мәктәп”, “Мәйдан” журналларында басыла. Бүгенге көндә дә җәмәгать эшләрендә актив катнаша. “Энергетик” мәдәният сараенда эшләп килүче “Замана” ансамбленә йөри. | Уйлар дулкынында: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2009.<br>Котлаулар, багышлаулар: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2009.<br>Кыйблам – мәхәббәт: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2009.<br>Йолдызнамә: шигырьләр. – Яр Чаллы, 2009. |
| 74 | **Фирая ХӘЛИУЛЛИНА**  | Фирая Хәлиуллинаның 1980 еллар башында шигырьләре республика һәм шәһәребез вакытлы матбугат битләрендә еш басыла. Бер бәйләм шигырьләре «Яшьлегем Чаллы» (1979), «Кызлар җыры» (1984), «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009) исемле күмәк җыентыкларда дөнья күрделәр. | |
| 75 | **Роза ХӘМИДУЛЛИНА**  | Роза Галимулла кызы Хәмидуллина-Гыйззәтуллина 1962 нче елның 14 октябрендә Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы Мулла Иле авылында туа. Туган авылында сигезьеллык, күрше Норлат авылында уньеллык мәктәптә белем ала. Алабуга мәдәни-агарту көллиятен һәм Яр Чаллы дәүләт педагогика институтының филология факультетын тәмамлый.<br>Хезмәт юлын Яшел Үзән районы Мәдәният идарәсе хезмәткәре булып башлап җибәрә. 1984 елдан алып хәзерге көнгә кадәр Яр Чаллы шәһәренең Муса Җәлил исемендәге үзәк китапханәсендә бүлек мөдире, әдәбият тарихы музее белән җитәкчелек итә,<br>2007 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсен җитәкли. | Сиңа илтә юлларым (Яшел Үзән төбәгенең тарихы һәм ономастикасы) / фәнни редактор Р. И. Хаҗиев. – Казан: Изд-во МОиН РТ, 2011.<br>Күңелем җырлый: хикәяләр, хатирәләр – Казан: Редакционно-издательский центр, 2014. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **76** | **Дөлфәт ХӘРБИ (1941-2013)**  | Дөлфәт Юныс улы Хафизов (Дөлфәт Хәрби) 1941 елның 1 апрелендә Татарстан Республикасының Мөслим районы Карл Либкнехт авылында туа. Туган авылында башлангыч, Күбәктә урта белем ала. 1963 елда Калининград хәрби-инженерлык училищесын, 1972 һәм 1981 елларда Мәскәүдә ике хәрби академия тәмамлый. 1966 елның 6 декабрендә Билгесез солдат кабере янында беренче салют бирү белән командалык итә. Дөлфәт Юныс улы тормышка һәм кешеләргә ышанычын һәм мәхәббәтен җуймаган. Җылы юмор белән язылган фәлсәфи-лирик шигырьләре, тормышны, бигрәк тә хәрби тормышны белеп язган хикәяләре аның киң эрудицияле һәм көчле рухлы кеше икәнлеген тасвирлыйлар.<br>Дөлфәт Хәрбинең беренче шигырьләре 1959 елда Мөслим районының «Колхоз байрагы» газетасында күренә башлый.<br>2013 елның 10 сентябрендә вафат була. | Тәрәзәңә чиртер мизгел: шигырьләр. − Яр Чаллы: «Яр Чаллы типографиясе», 1986.<br>И ашкынды күңел: шигырьләр. − Яр Чаллы: «Яр Чаллы типографиясе», 2002.<br>Ык елгасы талгын ага...: җырлар, такмаклар, шигырьләр. − Чаллы: «Яр Чаллы типографиясе», 2009.<br>Уфалла арбасы: җырлар / Д. Хәрби. − Алабуга: «Андерсен» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, 2010. |
| **77** | **Асия ХӘСӘНОВА**  | Асия Шаһимәрдән кызы Хәсәнова-Хәсәншина 1936 елның 8 ноябрендә Татарстан Республикасының Аксубай районы Иске Кармәт авылында туа. Туган авылында җиде сыйныфны, Иске Ибрай авылында ун сыйныфны тәмамлый. Урта белемле кыз Уралда яшәүче туганнары янына килә. Кияүгә чыга. 1957-1959 елларда бер-бер артлы ике балалары дөньяга килә. Хәсәновлар гаиләсе 1960 елда Мамадыш ягындагы Ак Чишмә авылына кайтып төпләнә. Унике ел авылда яшиләр, колхозда төрле эшләрдә эшли. Асия Хәсәнова җиде бала анасы.<br>1972 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши, мактаулы «Ана Даны» билгесенә лаек. | Күңелем хисләре: шигырьләр / кереш сүз Р. Бәшәр. − Яр Чаллы, 2005.<br>Сагыну таңнары: шигырьләр / кереш сүз М. Сафин, З. Нигманова. − Яр Чаллы, 2009.<br>Җанга шифа: шигырьләр. − Яр Чаллы, 2017. |
| **78** | **Рафис ХИСАМИ**  | Рафис Шәйхетдин улы Хисамиев (Рафис Хисами) 1944 елның 25 мартында Татарстан Республикасының Түбән Кама районы Ташлык авылында туа. Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлый.<br>1967 елдан Чаллы шәһәрендә яши. Шәһәр мәдәният йортына сәнгать җитәкчесе булып эшкә килә.<br>Рафис Хисамиев газеталарда шигырьләрен бастыра, концерт-кичәләрдә чыгышлар ясый, дәрте-куәте ташып торган «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең актив хәбәрчесе була. Олылар һәм балалар өчен шигырьләр яза. Композиторларыбыз Бату Мөлеков, Хәмит Булатов, Зөфәр Сәгыйтовлар тарафыннан аның бик күп шигырьләренә көйләр язылган. Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итә. | Җанымда уйный яшен: шигырьләр. – Чаллы: шәһәр типографиясе, 1995.<br>Исламнур: шигырьләр. – Чаллы: «Аргамак» журналы китапханәсе, 1998. – № 4.<br>Сагынулар шулдыр ул: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **79** | **Рәхим ХИСАМЕТДИНОВ**  | Рәхим Хисаметдинов Чаллыда яшәп иҗат итә. Камснаб оешмасында профсоюз председателе булып эшли. Шигырьләр яза, «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы була. 1980-1990 елларда шигырьләре шәһәр вакытлы матбугат битләрендә еш басылып килә. Аның бер бәйләм шигырьләре «Яшьлегем Чаллы» (1979) «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009) исемле күмәк җыентыкларда басылып чыга. Ләкин өметле каләм иясен вакытсыз үлем арабыздан алып китә. | |
| **80** | **Диләрә ХУҖИНА**  | Диләрә Хуҗина-Гыймалетдинова 1965 елның 28 ноябрендә Татарстан Республикасының Актаныш районы Иске Җияш авылында туа. Туган авылында урта белем алып, Алабуга мәдәният училищесына укырга керә. КАМАЗ заводларында хезмәт куя. Соңрак «Ак бүре» киностудисендә хисапчы булып, 1998 елларда «Кадыйр-фильм» киностудиясенең баш хисапчысы булып эшли. | |
| **81** | **Наилә ХӨРМӘТОВА**  | Наилә Гаскәр кызы Хөрмәтова 1963 елның 5 августында Әгерҗе районы Салагыш авылында туа. Туган авылында урта белем ала. Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. Республика һәм Чаллы шәһәре вакытлы матбугатында күп еллар журналист булып эшли.<br>Хәзерге көндә ул Төркиядә яши. | Бәхетле, диләр мине: шигырьләр. – Чаллы: 2000. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **82** | **Рәйсә ФӘХРАЗИЕВА (1956 – 2002)**  | Рәйсә Әхәт кызы Фәхразиева (Вәлитова) 1956 елның 22 июлендә Татарстан Республикасының Тукай районы Мусабай-Завод авылында туган. Борды урта мәктәбендә белем ала, шул ук мәктәптә укытучы булып эшли. Читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. Тукай районы «Якты юл» газетасында эшли. Соңыннан егерме елга якын туган авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Аның бер бәйләм шигырьләре «Яшьлегем Чаллы» (1979), «Кызлар җыры» (1977), «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009) исемле күмәк җыентыкларда басыла.<br>Рәйсә Фәхразиева 2002 елның 4 июнендә каты авырудан соң вафат була. | |
| **83** | **Нурзия ШАҺАБИЕВА**  | Нурзия Мифтахетдин кызы Шаһабиева-Сәлимҗанова 1961 елның 3 декабрендә Татарстан Республикасының Кукмара районы Тырыш авылында туа. 1977 елда Сәрдекбаш сигезьеллык мәктәбен тәмамлап, Арча педагогия училищесына укырга керә. 1981 елда, укуын бетереп, Зәй шәһәренә килә һәм «Дуслык байрагы» газетасында хезмәт юлын башлый. 1982 елда Чаллыга күчә һәм «Ләйсән» әдәби берләшмәсе утырышларына йөри. 1983 елда «Кама таңнары» газетасы битләрендә чыккан аның шигырьләре турында Хәниф Хөснуллин мондый юллар яза: «Нурзиянең күпчелек шигырьләрендә мәхәббәт, туган як турында сүз бара, тормыш хакында уйлану бар. Яшь авторның кайбер шигырьләре самимилеге белән игътибарны җәелеп итә».<br>Нурзия Шаһабиева алга таба Чаллыда мәгариф системасында озак еллар хезмәт итә. Хәзерге вакытта ул Чаллының Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназиясендә директор урынбасары булып эшли һәм шулай ук татар теле һәм әдәбияты дәресләре укыта. | Авылда кунакта: шигырьләр. – Яр Чаллы: «Мәгърифәт», 1999. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **84** | **Рәис ШАҺИ**<br> | Рәис Госман улы Шаһиев (Шаһи) 1954 елның 5 июлендә Татарстан Республикасының Мамадыш районы Югары Кыерлы авылында физика-математика укытучысы һәм үзешчән рәссам гаиләсендә беренче бала булып туа. 1961-1969 елларда авылның сигезьеллык һәм күрше Үсәли авылында 1971 елда унынчы классны тәмамлый.<br>1975 елның февраль аенда Чаллы шәһәренә килә. Шәһәр төзелеш идарәсенең 76-нчы төзелеш-монтаж идарәсенә рәссам-бизәүче булып эшкә урнаша. Ул балта остасы, бетончы булып хезмәт итә. 1990 елда «Чулман-Идел» («Шәһри Чаллы») газетасына рәссам-корреспондент булып урнаша. 1991 елда яңа оешкан «Аргамак» журналына техник-редактор буларак чакырыла. 1992 елда «КАМАЗ» газета-журнал нәшриятына техник-редактор булып күчә. 2006-2010 елларда «Мәйдан» журналында эшли.<br>1990 елларда Чаллы һәм Кама аръягы язучыларының график портретларын иҗат итә. Бу эшләре өчен 1993 елда Эдуард Касыймов исемендәге премия лауреаты була.<br>Рәис Шаһи шигырьләр яза. Бүгенге көндә ике мең ярымга якын башваткычлары, төрледән-төрле язмалары дөнья күрде. | Чаллы язучылары: портретлар һәм биографик белешмәләр: / Рәис Шаһи рәссам; Редакторы Рәшит Бәшәр. – Чаллы: «Мәгърифәт» кит. нәшр., 1998.<br>Кроссворды: чайнворды, кроссчайнворды, ребусы / Р. Шагиев. – Наб.Челны: Газетно-книжное изд. «КАМАЗ», 1999. –<br>Югары Кыерлы (Югары Бөрсет) авылы тарихы / Р. Шаһи, Н. Гариф. – Казан: ТФА Тарих институты басмаханәсе, 2013. –<br>Коммунизм тәмугы аша, – Казан: 2015<br>Онытмыйбыз, оныт-тырмыйбыз... кичермибез!!!. – Казан, 2016 |
| **85** | **Фәридә ШАКИРОВА**<br> | Фәридә Галимулла кызы Шакирова 1958 елның 2 гыйнварында Татарстан Республикасының Мөслим районы Яңа Сәет авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Туган авылында башлангыч мәктәп, аннан Мари-Бүләр мәктәбендә бишенче-алтынчы сыйныфларны, җиденче-сигезенче сыйныфны Татар Бүләр мәктәбендә укый. Соңыннан кичке урта мәктәпне тәмамлый.1973 –1976 елларда Минзәлә медицина училищесында шәфкать туташы белгечлеге ала. Аннан 1976 – 1978 елда Мөслим эшче яшьләр кичке мәктәбендә урта белем ала. Беренче хезмәт юлын Мөслим урта мәктәбендә шәфкать туташы булып хезмәтен башлап җибәрә. Шул ук вакытта Пионерлар йортында «Яшь санитарлар» түгәрәге алып бара. 1969 елда «Авыл утлары» газетасында «Кышкы этюд» шигыре басыла.<br>1982 елдан Яр Чаллы шәһәрендә яши. Фәридәнең 1997 елда шигырьләр туплаган «Асыл яр» дигән тәүге җыентыгы дөнья күрә. Яр Чаллы Язучылар оешмасы каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 1994 елдан бирле йөри. | Асыл яр: шигырьләр. – Яр Чаллы: «Хәерле иртә» нәшр., 1997. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 86 | **Айрат ШӘЙХЕТДИНОВ**  | Айрат Әсләхетдин улы Шәйхетдинов 1960 елын 11 маенда Татарстан Республикасының Минзәлә районының Куян авылында дөньяга килә. Айратның тормыш юлы гади: авыл мәктәбе, армия, КамАЗ заводы хезмәткәре.<br>1982 елдан Чаллы шәһәрендә яши. КамАЗ заводында эшли.<br>Айрат Шәйхетдинов туган ягының нечкә күңелле бер улы. Туган ягының урман-күлләре, таулары-болыннары, шаулап утырган иген кырлары – һәммәсе дә аның өчен изге җирләр. «Туган ягым» шигырендә читтә яшәүче әдәби герое:<br>Яр Чаллы Язучылар оешмасы каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 2014 елдан бирле йөри. | Җылы дулкын җанны били: шигырьләр. – Казан:2015. |
| 87 | **Рамил ШӘМСЕТДИНОВ**  | Рамил Шщйхетдин улы Шщмсетдинов 1957 елның 22 июлендә Татарстан Республикасының Мөслим районы Бүләк авылында туа. Туган авылында дүрт сыйныф, күрше Урәзмәт авылында урта белем ала. Аннан Минзилә техник училищесын тәмамлый. 1976-1978 елларда армия сафында Куйбышев өлкәсендә хезмәт итә.<br>1979 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши. КамАЗның тимерчелек заводында хезмәт итә.<br>Яр Чаллы Язучылар оешмасы каршында оешкан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә 2015 елдан бирле йөри. | |
| 88 | **Сәлимә ШӘРИПОВА**  | Сәлимә Сафиулла кызы Шәрипова 1940 елның 7 гыйнварында Татарстан Республикасының Тукай районы Ташкичү авылында туган.<br>Бер бәйләм шигырьләре «Җиде юл үзәне» (1975), «Кызлар җыры» (1977), «Яшьлегем Чаллы» (1979), «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009) исемле күмәк җыентыкларда басылып чыкты.<br>Бүгенге көндә Чаллы шәһәрендә яши. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **89** | **Фәйрүзә ШӘРИПОВА**<br> | Фәйрүзә Фәиз кызы Шәрипова, 1957 елның 19 ноябрендә Сарман районы (хәзерге Тукай районында) Теләнче Тамак авылында хезмәткәр гаиләсендә туган.<br>Урта белемне туган авылында ала. Мәктәптә укыганда, 5нче сыйныфтан 10нчы сыйныфка кадәр пионервожатый була, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Югары сыйныфларда укыганда, мәктәп музеенда 2 ел лектор эшләрен алып бара. Мәктәп елларында ук шигырьләр язарга, рәсем ясарга ярата. Мәктәптә бер генә стенгазета да аннан башка чыкмый. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Тамбов шәһәренең медучилищесында шәфкать туташына укый. 1976 нчы елдан алып Яр Чаллыда 7нче санлы балалар бакчасында эшли.<br>1998 нче елда Казан Дәүләт педагогия университетының филология факультетын читтән торып укып тәмамлый. 2006 елдан хәзерге көнгә кадәр шәһәрнең 8нче мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.<br>2011 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмә әгъзасы. | |
| **90** | **Рәшит ЮНЫСОВ**<br>**(1930-2011)**<br> | Рәшит Юныс улы Юнысов 1930 елның 14 апрелендә Татарстан Республикасының Тукай (элеккеге Чаллы) районы Биклән авылында туа. Биклән урта мәктәбендә 8 ел укыганнан соң, Алабуга мәдәният-агарту училишесына укырга керә. Уку йортын 1950 елда кызыл дипломга тәмамлый. 1954-1958 елларда шул ук шәһәрдә педагогия институтында укып, югары белем ала.<br>Рәшит Юнысов институт тәмамлаганнан соң Әгерҗе һәм Тукай районы мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты, физкультура укыта. Әгерҗе районы Яңаул мәктәбендә директор (1958-1963) булып эшли.<br>КАМАЗ төзелеше башлангач 1972 елның феврalendә Чаллыга күчеп килә. Аның юмористик шигырьләре һәм хикәяләре республикабызда чыгып килүче газета-журналларда 1954 елдан башлап даими басылып киләләр. Альберт Хәсәнов белән берлектә «Хәтфә», «Күршем миңа кыз димләде», «Мәхәббәт утларың», «Син кайгырма дустым еракта» дигән җырларын иҗат итәләр. Аеруча «Хәтфә» җыры зур популярлык казана.<br>Рәшит Юныс улы 2011 елда вафат булды. | |